КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1126

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $4.1.27^1$ нче пункт өстәргә:

«$4.1.27^1$. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тәкъдиме белән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының (алга таба – депутатлар) сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны – депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары тарафыннан бирелә торган урыннар исемлеген, шулай ук әлеге урыннарны бирү тәртибен билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин